МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2017 г.Казань № 117/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерык преамбуласында һәм текст буенча алга таба “Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы” сүзләрен “2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Боерык белән расланган Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 3.1.21. пунктында “КФХ урнашу урыны буенча салым органына исәпкә кую турында таныклык күчермәсе” сүзләрен “Салым түләүченең индивидуаль номеры таныклыгы күчермәсе” сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәгә 3, 8, 11 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру турында нигезләмә
(2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы редакциясендә)
3 нче кушымта

**Бизнес-планның тәкъдим ителә торган формасы**

Титул бите

1.Резюме (проект турында кыскачы мәгълүмат)

Крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) турында төп мәгълүмат;
КФХның тулы исеме;
факттагы адресы;
элемтә телефоны;
КФХ башлыгының кыскача резюмесы;
фамилиясе, исеме, атасының исеме;
туу датасы;
белеме;
паспорт мәгълүматлары;
КФХ эшкуарлык эшчәнлегенең төп төре:

2. Проект тасвирламасы

грант алу өчен эшчәнлек юнәлеше (сайлап алырга):
сөт;
ит,
атчылык,
яшелчәчелек,
бөртекле һәм бөртекле-борчаклы культуралар җитештерү;
җимешле һәм җиләкле культуралар үстерү;
авыл хуҗалыгы кошчылыгы;
бәрәңге үстерү;
дуңгызчылык;
сарык һәм кәҗә үрчетү.
Проектның максаты;
Территориясендә КФХ эшчәнлеге алып барыла (алып бару планлаштырыла) торган авыл җирлеге атамасы;
Проектның социаль – икътисадый әһәмияте;
Бина, җир кишәрлеге мәйданы;
Аренда, аена 1 кв. метр өчен аренда бәясе.

1 нче таблица

Җитештерлә торган продукция, эш, хезмәт күрсәтүләр җыелмасы

| Т/б № | Исеме |
|---|---|
| | |

Төп кулланучылар;

Салым салу системасы төре.

## 3. Проектның финанс структурасы

2 нче таблица

Чыгымнар планы

мең сум.

| Т/б № | Товар, күрсәтелә торган хезмәтләр, башкарыла торган эшләр исеме | Саны | Берәмлек өчен бәясе | Гомуми бәясе | Бәя түләү (финанслау чыганаклары) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Грант (яки бер тапкыр бирелә торган ярдәм) | Үз чаралары | Заем чаралары |
| 1 | 2 | | | 3 | 4 | 5 | 6 |
| I. Крестьян (фермер) хуҗалыгы үсеше белән бәйле чыгымнар | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | I бүлек буенча барысы | | | | | | |
| II. Крестьян (фермер) хуҗалыгын көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнар | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | II бүлек буенча барысы | | | | | | |
| | Чыгымнар планы буенча барысы | | | | | | |

3 нче таблица

Чыгымнар (проектны гамәлгә ашыру чорында еллар буенча)

| /б № № | Исеме | Суммасы, сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ |
| 1 | Чимал (запас өлешләр, орлыклар, азыклар) | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Коммуналь түләүләр:<br>-электр энергиясе<br>-су белән тәэмин итү<br>-җылылык энергиясе<br>-газлаштыру<br>-канализация | | | | | |
| 3 | Хезмәт хакы | | | | | |
| 4 | Даими эш урыннары саны, кеше | | | | | |
| 5 | Аренда | | | | | |
| 6 | Салым күчерүләре | | | | | |
| 7 | РФ Пенсия Фондына күчерүләр | | | | | |
| 8 | Бүтән чыгымнар | | | | | |
| | Барысы: | | | | | |

4 нче таблица

Җитештерү һәм гамәлгә ашыру планы (проектның һәр елына)

Үсемлекчелек

| т/б № | Продукция исеме | Мәйдан, гектар | Уңыш, центнер/га | Тулаем җыем, тонна | Товар продукция күләме тонна | Бәясе, мең сум/ тонна | Сатудан табыш |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | Барысы: | | | | | | |

5 нче таблица

Терлекчелек (проектның һәр елына)

| т/б № | Продукция исеме | Терлек башы, баш | Савым/артым, кило-грамм /баш | Тулаем продукция күләме, тонна | Товар продукция күләме тонна | Бәясе, мең сум/ тонна | Сатудан табыш |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | |
| | Барысы: | | | | | | |

Әгәр эш башлаучы фермер хезмәтләр күрсәтергә яки нинди булса да эшләр башкарырга планлаштыра икән, аларны сатудан табышны исәпләүне 4, 5 таблицаларга туры килә торган рәвештә башкарырга кирәк.

6 нчы таблица

Эшчәнлек юнәлешләре буенча сатудан табыш (проектны гамәлгә ашыру чорында еллар буенча)

| Исеме | Суммасы, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ | 20__ |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барысы: | | | | | |

7 нче таблица

Проектны гамәлгә ашыру чорында эшкуарлык эшчәнлегенең төп финанс-икътисадый күрсәткечләре динамикасы

| т/б № | Исеме | Суммасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Грант суммасы | |
| 2. | Үз чаралары | |
| 3. | Заем чаралары | |
| 4. | Проект куәтенә чыкканчы сатудан табыш | |
| 5. | Проект куәтенә чыкканнан соң сатудан табыш | |
| 6. | Төп кирәк-яракларны сатып алуга чыгымнар | |
| 7. | Җитештерүгә һәм гамәлгә ашыруга тотылган чыгымнар | |
| 8. | Барлык чыгымнар | |
| 9. | Керем | |
| 10. | Рентабельлелек | |

8 нче таблица

Акчаларны куллану сроклары

| т/б № | Исеме (төзелеш эшләре, ферманың техник комплектлануы, тиешле баш саннары булу һ.б.ш.) | Проектны гамәлгә ашыру сроклары* | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | | |
| | | 3 кв. | 4 кв. | 1 кв. | 2 кв. | 3 кв. | 4 кв. |
| 1 | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | |
| 7 | _____ башка каралган ферманы кулланышка кертү | | | | | | |

*кварталлар буенча млн.сумда тотылган акчалар суммасы (үз һәм (яки) кредит) күрсәтелә.

Бизнес - план рентабельле җитештерү алып баруны, сатыла торган авыл хуҗалыгы продукциясенең күләмен арттыруны һәм грантның һәр 500 мең сумына крестьян (фермер) хуҗалыгында кимендә бер эш урыны булдыруны күздә тота, шулай ук крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грант һәм көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм хисабына финанслашу өчен тәкъдим ителә торган чыгымнар планын үз эченә ала.

Крестьян (фермер)
хуҗалыгы башлыгы_____________________________ ___________________________
(фамилиясе,исеме, атасының исеме) (имза)

Крестьян (фермер) хуҗалыкларын
төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру
турында нигезләмә
(2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-
төлек министрлыгы редакциясендә)
8 нче кушымта

**“2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” программасы буенча КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант бирү турында шартнамә**

№ 00000000082178900002/ _____

Казан ш. 20 ___елның __________

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы исеменнән, алга таба “Грант бирүче” дип йөртеләчәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып эш йөртүче Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Әхмәтов Марат Готыф улы, бер яктан, дәүләт теркәвенә алу турында таныклык нигезендә эш итүче, ОГРНИП - ________________, Татарстан Республикасы______________________ муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыгы, алга таба “Грант алучы” дип йөртеләчәк, икенче яктан, икесе бергә “Яклар” дип йөртеләләр, конкурс йомгаклары буенча (конкурс комиссиясе утырышының 20___ елның “______” _____________ №___________ беркетмәсе, бюджет акчаларын бүлеп бирү турында Грант бирүченең 20__ елның “______” _____________ №___________ боерыгы) түбәндәге турында әлеге Шартнамә төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Грант бирүче Грант алучыга ________________________________________________________________
(эшчәнлек юнәлеше)

өчен КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант бирә.

1.2. Грант алучы грант акчаларын конкурс комиссиясе тарафыннан расланган чыгымнар планы нигезендә тотарга йөкләмә ала.

1.3. Грант суммасы Грант бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең (алга таба – Идарә) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлегендә ачылган хосусый счетына, ә Идарә тарафыннан Грант алучының Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы

буенча идарәсе территориаль бүлегендә ачылган хосусый счетына күчерелә һәм ________ (______________________) сум тәшкил итә.
(суммасы язмача)

1.4. Шартнамәнең казначылык органнары катнашында гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына федераль бюджет турында” Федераль законда каралган очракларда Россия Федерациясе валютасында акчалар хәрәкәтендә казначылык органнарының катнашуы кагыйдәләрен раслау хакында” 2016 елның 30 декабрендәге 1552 номерлы карары нигезендә башкарыла.

## 2. Грант бирүченең хокуклары һәм бурычлары

2.1. Грант бирүче:

Грант алучы тарафыннан аңа әлеге Шартнамә нигезендә йөкләнгән бурычларның үтәлешен тикшереп тора;

Грант алучыдан проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы финанс һәм беренчел исәпкә алуга кагылышлы башка документларын соратып ала;

бары тик проектны гамәлгә ашыру өчен грант чыгымнарын раслау өчен Грант алучы тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә, шулай ук проектның чынбарлыкта гамәлгә ашырылуын тикшерә;

Грант алучыга карата “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасы таләпләрен бозуларны бетерүгә һәм аларның үтәлүен тәэмин итүгә юнәлтелгән Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Шартнамәдә каралган гамәлләр башкара.

2.2. Финанслау лимитлары булганда, әлеге Шартнамә төзелгән вакыттан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Грант алучыга акчаларны күчерү юлы белән грант суммасын түләүне башкара.

2.3. Грант алучы тарафыннан “2017 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2017 елның 10 февралендәге 77 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында каралган грант бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу, шул исәптән әлеге шартнамә нигезендә Грант алучы тапшырган документларда дөрес булмаган белешмәләр бирелү факты (фактлары) билгеле булган яки бу хакта Дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынган очракта, күрсәтелгән хокук бозуларны бетергәнгә кадәр грант бирүне туктатып тора, бу хакта, туктатып тору турында карар кабул иткән датадан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Грант алучыга хәбәр итү мәҗбүри.

## 3. Грант алучыны хокуклары һәм бурычлары

3.1.1. Бюджет процессында катнашмаучының операцияләрен исәпкә алу өчен Федераль казначылыкның территориаль органында счет ача;

3.1.2. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган чыгымнарны санкцияләүне гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылыкның территориаль органына Россия Финанс министрлыгының “2017 елга, 2018 һәм

2019 еллар план чорына федераль бюджет турында" Федераль законда каралган очракларда Россия Федерациясе валютасында акчалар хәрәкәтендә казначылык органнары катнашканда Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан операцияләрне санкцияләүне уздыру тәртибе хакында" 2016 елның 28 декабрендәге 244н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе валютасында акчалар хәрәкәтендә казначылык органнары катнашканда Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан операцияләрне санкцияләүне уздыру тәртибендә каралган документлар тапшыра;

3.1.3. Түләү, исәп-хисап документларында һәм акча түләү йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документларда федераль бюджет акчаларын баш бүлүче белән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең иң югары органы арасында төзелгән максатчан субсидия бирү турында килешү идентификаторын (00000000082178900002) күрсәтә.

3.1.4. Идарәгә түбәндәге документлар тапшыра:

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алуларның һәр исеме бәясенең кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түләнүен раслый торган документларның Министрлык боерыгы белән расланган формасы буенча, күрсәтелгән документларның күчермәләрен (түләү йөкләмәләренең, шартнамәләрнең, накладнойларның, счет-фактураларның, ветеринария документларының, сатып алуларны дәүләт теркәве турында документларның күчермәләрен, ферманың эчке һәм тышкы яклары төшерелгән фоторәсемнәрне) беркетеп, җыелма реестрны;

максат чыгымнарын түләүгә түләү йөкләмәләрен, КФХның максат чыгымнары буенча йөкләмләре барлыкка килүгә нигез булган шартнамәләрне, аларда эш башкаручының (подрядчының, товар китерүченең) тулы исеме һәм товарның (хезмәт күрсәтүнең) исеме, чыгымнар планында каралган грант чикләрендәге суммага аларның саны (күләме) күрсәтелә;

3.1.5. Грант хисабына башкарыла торган операцияләрнең аерым-аерым аналитик исәбен алып барырга йөкләмә ала;

3.1.6. 1.1, 1.2., 3.1. пунктлар нигезендә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә һәм (яки) башка күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә;

3.1.7. Грант акчаларын тотып бетергән көннән башлап 5 ел дәвамында КФХ башлыгы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) "Эшчәнлек турында белешмәләр" формасы буенча грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында яртыеллык һәм еллык хисаплар тапшыра. Хисаплар Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча грант алучы тарафыннан хисап чоры беткәннән соңгы 10 көнлек срокта тапшырыла. Идарәләр хисаплар алганнан соңгы 10 көнлек срокта аларны килештерә һәм Министрлыкка тәкъдим итә;

3.1.8. Грант алган көннән соңгы 18 ай дәвамында Министрлыкка "Җыелма реестр" формасы буенча, хисап документларын беркетеп, грант акчаларының максатка ярашлы тотылуы турында йомгак хисап тапшыра. Хисап документларына законнар нигезендә шундый документлар дип танылган

документлар (товарлар һәм (яки) хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне һәм аларны алуны раслый торган документлар, фоторәсемнәр) кирә. Хисаплар Грант алучы имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) таныкланган һәм Татарстан Республикасы ________________________ муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы белән килештерелгән булырга тиеш.

3.1.9. Грант акчаларын тотып бетергәннән соң кимендә биш ел дәвамында авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

3.1.10. Грант алган елда грант ярдәменең һәр 1 млн. сумына кимендә бер даими яңа эш урыны булдыра, әмма бер грантка кимендә кимендә бер даими яңа эш урыны, һәм аларны грант акчаларын тотып бетергән көннән соңгы кимендә 5 ел дәвамында саклап кала;

3.1.11. Хосусый счетына акчалар килгән көннән алып 18 ай эчендә грант акчаларын тота;

3.1.12. Чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алулар исемнәре бәясенең кимендә 10%ын үз акчалары исәбеннән түли;

3.1.13. Авыл хуҗалыгы продукциясенең артымын грант бирелгән елга кадәрге елга караганда 10 процент дәрәҗәсендә булуны тәэмин итә;

3.1.14. Грант алучының гранттан файдалану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Грант бирүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр уздырылуга ризалык бирә.

3.2. Грант алучы бюджет процессында катнашмаучының операцияләрен исәпкә алу өчен Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган хосусый счетка чыгымнар планында күрсәтелгән проектның кимендә 10 процентын тәшкил иткән үз акчаларын якларның үзара килешүе буенча күчерә.

3.3. Грант акчаларына сатып алынган активлар Грант алучы исеменә теркәлгән булырга һәм аның тарафыннан Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы территориясендә кулланылырга тиеш.

3.4. Грант алучы тарафыннан грант акчаларына сатып алынган мөлкәт грант акчаларын тотып бетергән көннән 5 ел дәвамында бүләк ителергә, арендага тапшырылырга, башка затлар файдалануына бирелергә, алмаштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яисә законнар нигезендә башка төрле тартып алынырга тиеш түгел.

3.5. Алынган акчалар хисабына Грант алучыга түбәндәгеләрне башкару тыела:

3.5.1. Чит ил валютасын сатып алу, моңа югары технологияле импорт җиһазларын, чимал һәм комплект әйберләрен сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә башкарыла торган операцияләр, шулай ук әлеге акчаларны башка операцияләргә бирү максатларына ирешү белән бәйле булган операцияләр керми;

3.5.2. Башка юридик затның устав (гамәлгә кую) капиталына, башка юридик затның (юридик зат тарафыннан оештырылган җәмгыятькнең) мөлкәтенә, максатчан акчаларны бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны күрсәтелгән юридик затка (юридик зат тарафыннан оештырылган

җәмгыятькә) анның өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә, кредит оешмасында ачылган счетларына күчерү мөмкинлеге каралмаган булса, юридик затның (юридик зат тарафыннан оештырылган җәмгыятькнең) устав (гамәлгә кую) капиталын арттырмый торган кертем буларак сарыф итү;

3.5.3. Әгәр федераль законнарда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең башка норматив хокукый актларында башкасы билгеләнгән булса, акчаларны депозитларга, шулай ук башка финанс коралларына урнаштыру (күрсәтелгән акчаларны, аларны урнаштырудан алынган акчаларны да кертеп, соңыннан бюджет процесында катнашмаучының операцияләрен исәпкә алу өчен ачылган хосусый счетларга кайтару белән бергә) максатларында тоту;

3.5.4. Банкта Грант алучыга ачылган счетларга күчерү, моңа түбәндәгеләр керми:

3.5.4.1. Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә Грант алучының йөкләмләрен түләү;

3.5.4.2. Түләнергә тиешле акчаларны һәм социаль түләүләрне, хезмәткәрләр файдасына башка түләүләрне, шулай ук грант алучы штатында булмаган, әмма максатчан акчалар бирелгәндә билгеләнгән максатка ирешү өчен җәлеп ителгән затларга түләнгән акчаларны исәпкә алып, хезмәт өчен түләү буенча Грант алучының йөкләмләрен түләү;

3.5.4.3. Максатчан акчаларны санкцияләү тәртибендә каралган эшләрнең башкарылу, хезмәтләрнең күрсәтелү, товарларның китерелү фактларын раслый торган документлар, максатчан акчалар бирү тәртибен җайга сала торган дәүләт контрактларында, учреждениеләр контрактларында, шартнамәләрдә, килешүләрдә яки норматив хокукый актларда каралган башка документлар тапшыру шарты үтәлгәндә, финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган Грант алучы тарафыннан чынбарлыкта башкарылган эшләрне, күрсәтелгән хезмәтләрне, китерелгән товарларны түләү;

3.5.4.4. Әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән документларны һәм Грант алучының чыгымнарын (чыгымнарның бер өлешен) раслый торган түләү йөкләмәләренең, түләү йөкләмләре реестрларының күчермәләрен тапшыру шарты үтәлгәндә, Грант алучының чыгымнарын (чыгымнарның бер өлешен) каплау.

3.5.5. Шартларында аванс түләүләре каралган шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү кысаларында Грант алучы белән контрактлар, шартнамәләр төзегән юридик затларга банкларда ачылган счетларга күчерү, моңа түбәндәге контраклар, шартнамәләр керми:

3.5.5.1. Элемтә хезмәте күрсәтүләрне, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне, электр энергиясен, авиация һәм тимер юл билетларын, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү билетларын сатып алу, басма матбугатка язылу, арендалау максатларында, шулай ук юридик затларныкы булган инженерлык челтәрләрен, коммуникацияләрне, корылмаларны күчерү буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшләр башкару максатларында төзелә торган;

3.5.5.2. Федераль бюджет яки автоном учреждениеләр белән төзелә торган.

3.6. Гранттан файдалануга йомгак ясап, Грант алучы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының тармак бүлекләре, аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге һәм эш башлаучы фермаларга ярдәмгә грант бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары проектларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе рәисе белән берлектә грантның максатчан билгеләнеше буенча тотылуы турында “Килештерү кәгазе”н имзалыйлар.

## 4. Яклар җаваплылыгы

4.1. Яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз йөкләмәләре буенча җаваплы була. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә гранттан файдалану шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне тикшерәләр.

4.2. Шартнамәнең 3.1. пунктында билгеләнгән грантлар бирү максатлары һәм шартлары бозылган, грантларның максатчан билгеләнеше буенча кулланылмавы йә грант алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу фактлары ачыкланган очракта, бирелгән грантлар Министрлыктан тиешле таләпләр алынган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

4.3. Грант алучы тарафыннан Министрлыкка һәм Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык Грант алучыга йөкләнә.

4.4. Күрсәтелгән акчаларны бюджет кеременә ихтыярый кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

4.5. Шартнамәне гамәлгә ашыру барышында барлыкка килергә мөмкин низаглар Якларның үзара сөйләшүе юлы белән хәл ителергә тиеш.

Низагларны үзара сөйләшү юлы белән хәл итеп булмаган очракта, алар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителергә тиеш.

4.6. Яклар Шартнамәдә каралган бурычларын тулысынча яки өлешчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан бары тик форс-мажор шартлар барлыкка килгәндә генә азат ителәләр (РФ ГК ның 401 ст., 3 п.). Ләкин мондый шартлар барлыкка килгәндә, әгәр алар беткәннән соң бурычларны үтәү мөмкинлеге сакланып калса, Грант алучының йөкләмәләре үзләреннән үзләре туктатылмый.

4.7. Шартнамә, ахырдан бюджет законнары нигезендә тиешле бюджетка ________________ мең сум күләмендәге грантны кире кайтаруны күздә тотып, Якларның үзара ризалыгы белән вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

4.8. Шартнамәне Грант бирүче таләбе буенча суд тәртибендә өзү Россия Федерациясе Граждан кодексының 450 статьясы нигезендә түбәндәге очракларда башкарыла:

1) грант куллану һәм Шартнамә йөкләмәләрен үтәү турында хисаплар Грант алучы тарафыннан бөтенләй тапшырылмаганда яки тулы булмаган күләмдә тапшырылганда;

2) Грант бирүче хисап документларын тикшергәндә Грант алучы биргән белешмәләрнең махсус бозып бирелүе ачыкланганда;

3) грант акчаларының максатчан кулланылмавы ачыкланган очракларда;

4) Грант алучының эшчәнлеге биш ел эчендә туктатылган һәм (яки) Грант алучының проектны гамәлгә ашыру буенча үзенә алган йөкләмәләрен үтәмәве очрагында;

5) әгәр проект Шартнамә төзегән көннән 18 ай эчендә гамәлгә ашырылмаса, моңа җитди сәбәпләр булмаганда (җиңеп булмаслык көч, ягъни гадәттән тыш шартлар (җир тетрәү, давыл, су басу, янгын һ.б.), авыру яки имгәнү аркасында Грант алучының 18 айдан артык озак вакыт дәвамында вакытлыча эшкә сәләтсез булуы, якын туганының сәламәтлеге бозылу сәбәпле аны карау таләп ителү).

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Шартнамә аңа кул куелган көненнән үз көченә керә һәм үз йөкләмәләрен тулысынча үтәп бетргәнче гамәлдә була.

5.2. Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Яклар тарафыннан имзалана торган өстәмә килешүне язма рәвештә тутыру юлы белән Якларның үзара ризалыгы белән кертелә.

5.3. Шартнамә, Якларның һәркайсына берәр нөсхә булырлык итеп, ике нөсхәдә төзелде, икесе дә тигез юридик көчкә ия.

## 6. Якларның реквизитлары һәм имзалары.

| Грант бирүче: | Грант алучы: |
|---|---|
| | ________________________________________ |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | ________________________________________<br>теркәлү адресы ________________________<br>________________________________________ |
| 420014, Россия, Татарстан Республикасы, Казан ш., Федосеевская ур., 36 й. | яшәү адресы ___________________________<br>________________________________________ |
| р/с 40601810322022000048 в ГРКЦ НБ РТ банка России<br>БИК 049205001<br>УФК по РТ (Минсельхозпрод РТ – л/сч. ЛБ 007090001 Аппарата МСХиП)<br>ИНН 1654019555<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1021602854580 | паспорт: серия ______, №______________<br>________________________________бирелгән<br>Бирелү датасы__________________________<br>р р/с УФК по РТ 40601810322022000048 в ГРКЦ НБ РТ банка России<br><br>ИНН УФК 1654042748<br>КПП УФК – 165501001, БИК – 049205001;<br>л/сч. 41__________________________________<br><br>ОГРНИП (ОГРН)_____________________ |

КФХ башлыгы ИНН ___________________

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

М.Г.Әхмәтов ___________________ ___________________ ___________
(имза) (ф.и.а.и.) (имза)

Мөһер урыны __________, 20__ел. Мөһер булган очракта _____________, 20___ел

Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм
үстерүгә конкурс уздыру турында нигезләмә
(2017 елның 30 мартындагы 66/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы редакциясендә)
11 нче кушымта

"2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм" ведомство максатчан программасында катнашучы
ТР ________________________________________ муниципаль районының
__________________________________________________________
(КФХ исеме)

**йөкләмәсе**

КФХ счетына акча күчкән көннән алып 18 ай эчендә грант акчаларын кулланып бетерү турында;

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр бәясенең кимендә 10 процентын үз акчаларыннан түләү турында;

алынган Грант акчаларының әлеге "Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру турында нигезләмә"дә каралмаган максатларда яки аның акчаларын куллану сроклары бозылып тотылган очракта, шулай ук КФХ бетерелгән яки Грант акчаларына сатып алынган мөлкәт тартып алынган (бүләк ителгән, арендага тапшырылган, алыш-биреш ясалган яки пай рәвешендәге кертем, гади кертем буларак кулланылган яисә башка төрле тартып алынган) очракта, грант акчаларын Грант бирү турындагы шартнамәнең гамәлдә булуның биш еллык срогы беткәнче тиешле бюджетка кире кайтару турында;

грант алган елда грантның һәр 1 млн. сумына кимендә бер яңа даими эш урыны, әмма кимендә бер яңа даими эш урыны булдыру турында;

яңа даими эш урыннарын грант акчаларын кулланып бетергән датадан кимендә 5 ел дәвамында саклап торырга;

грант алган КФХ тарафыннан сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләменең еллык артымы кимендә 10 процент булу турында;

грант акчаларын кулланып бетергән датадан соң кимендә 5 ел дәвамында финанс-хуҗалык эшчәнлеген башкару турында;

мин башлык булган хуҗалыкның урнашу һәм теркәлү урыны буенча муниципаль берәмлектә яшәвем яки анда даими яшәү урынына күчеп кайтырга тиеш булуым турында һәм әлеге хуҗалыкның грант алган һәм акчасын кулланып бетергән датадан кимендә 5 ел дәвамында бердәнбер эш урыным булуы хакында.

КФХ башлыгы _________ ___________________ ____________, 20 __ ел
имза (Ф.И.А.и.) (дата)

Мөһер урыны (мөһер булган очракта)